**СОВЕТ СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу, ул. Школьная, 9а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**25 август 2021 ел** **№ 37**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законы, Биектау районы прокуратурасының 27.05.20021 ел, № 02-01-26-2021 таләбе нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмә» гә Суыксу авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 24 нче номерлы карары белән расланган (Советның 22.04.20021 ел, № 27 карары редакциясендә) 3 бүлекнең 3.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«3.6. Эшләрне башкаруга рөхсәт алган очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларны кискән өчен компенсация бәясе күләмендә түләүләр кертергә тиеш.»;

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарастан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.С.Низамиев